СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

КАРАР КАРАР

06.09.2018 с.Ямбулатово № 45 – 191

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Ямбулат авылы җирлеге Советының
«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советы карары, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 16 апрелендәге 30-171 номерлы карары нигезендә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең әлеге проектны гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында,

Югары Ослан муниципаль районының
Ямбулат авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проектын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе 2 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында” карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе 3 нче кушымта нигезендә.

3. “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында” Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советы карары проекты буенча халык алдында тыңлауларны 2018 елның 12 октябрендә 10.00 сәгатьтә авыл мәдәният йорты бинасында, Ямбулатово авылы, Казан урамы, 2А йорт адресы буенча уздырырга

4. Башкарма комитетка Ямбулат авыл җирлегендә яшәүчеләрнең кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

5. 2018 елның 10 сентябренә кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Ямбулат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.Н. Әхмәтҗанов